ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункт өстәргә:
«$3^2$. Электр двигательләре генә куелган җиңел машиналар, мотоцикллар, мотороллерлар, автобуслар, йөк автомобильләре үзләренә теркәлгән салым түләүчеләр алар өчен салым салудан азат ителәләр.»;

2) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:
«3) электр двигательләре генә куелган җиңел машиналарга, мотоциклларга, мотороллерларга, автобусларга, йөк автомобильләренә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2029 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы $3^2$ пункты нигезләмәләре 2028 елның 31 декабренә кадәр (шул көнне кертеп) кулланыла.

4. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 4 пунктының 3 пунктчасы нигезләмәләре 2030 елның 31 декабренә кадәр (шул көнне кертеп) кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 28 сентябрь
№79-ТРЗ